Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Оет торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

19.11.2025 № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олы Шыңар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Совет карарлары нигезендә Олы Шыңар авыл җирлегенең 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына таянып 2025 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыенында «Сез Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлегенең Оет торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Оет торак пункты - грунт эшкәртү, комлы нигез салу, нигезне вак таштан ясау, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 157 кеше кертелгән, җыенында катнашучылар саны 80 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның 80 тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Оет торак пунктында гражданнар җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дерес дип танырга.
2. "Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлегенең Оет торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Оет торак пункты - грунт

эшкәртү, комлы нигез салу, нигезне вак таштан ясау, юл кырыен төзү, су үткәрү торбаларын урнаштыру, эшләр ечен килешү буенча түләү)

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.
4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү ечен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов